КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 27 апрель г.Казань № 342

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 июль, 620

нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чыгымнарны финанслашуга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 31 июль, 620 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 ел, 15 ноябрь, 1041 нче.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 27 апрель, 342 нче
карары белән расланды

Индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү һәм бүлү тәртибе

1. Әлеге Тәртип индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар (алга таба – башка бюджетара трансфертлар) бирү һәм бүлү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2017 – 2020 елларга Татарстан Республикасы территориясендә муниципаль дәрәҗәдәге индустриаль (сәнәгать) парклар (парклары) һәм сәнәгать мәйданчыкларын оештыру һәм үстерү» ярдәмче программасы чараларын тормышка ашыру кысаларында индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тоту өлешендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм

итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә.

3. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга тиешле финанс елына министрлыкка җиткерелгән башка бюджетара трансфертлар бирү турында карары белән билгеләнгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Башка бюджетара трансфертлар бирү өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрен сайлап алу критерийлары түбәндәгеләр була:

индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә җитештерү эшчәнлеген алып бара торган кимендә ике теркәлгән резидент булу;

индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә эшчеләр саны – кимендә 20 кеше;

Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органында индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы эшен оештыру буенча бүлекчә (бүлек) булу.

6. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансфертлар түбәндәге шартларда бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актлары таләпләре нигезендә финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган индустриаль (сәнәгать) паркларын һәм сәнәгать мәйданчыкларын карап тотуга бәйле чаралар исемлеген раслау турында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының муниципаль хокукый акты булу;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетында (җирле бюджетның җыелма бюджет язмасында) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре булу, финанслашу максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган күләмдә, Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансферт бирү планлаштырыла торган күләмне дә кертеп, аларны гамәлгә ашыру өчен кирәк булган күләмдә;

Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына башка бюджетара трансферт бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзү, аларны финанслау максатларында башка бюджетара трансферт бирелә торган чыгым йөкләмәләрен үтәү буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге йөкләмәсен һәм килешүдә каралган йөкләмәләрне үтәмәгән өчен җаваплылыкны күздә тота.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары арасында

башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

8. Башка бюджетара трансфертны куллануның нәтиҗәлелек (нәтиҗәләре) максатчан күрсәткече – индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә теркәлгән резидентлар санын узган елның хисап чорына карата арттыру.

9. Башка бюджетара трансфертны алу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары Министрлыкка түбәндәгеләрне кертә:

Министрлык раслый торган форма буенча башка бюджетара трансферт бирүгә гариза;

индустриаль (сәнәгать) паркның (паркының) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгының гамәлгә кую документлары күчермәләре;

индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә җитештерү эшчәнлеген алып баручы кимендә ике теркәлгән резидент булуны раслый торган документлар күчермәләре;

индустриаль (сәнәгать) парк (паркы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы территориясендә кимендә 20 эш урыны булуны раслый торган документлар күчермәләре;

индустриаль (сәнәгать) паркны (паркын) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгын карап тотуга бәйле эшләрне гамәлгә ашыру өчен финанс ихтыяҗына нигезләү һәм аның исәп-хисабы.

Документлар Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан кәгазь һәм электрон чыганакларда кертелә.

10. Министрлык:

башка бюджетара трансферт бирүгә гаризаны кабул ителгән көнне гаризаларны теркәүгә алу журналында терки;

гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм башка бюджетара трансферт бирү турында яки башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

11. Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Тәртипнең 9 пунктында күрсәтелгән документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

тапшырылган документлар, алардагы мәгълүматлар бу Тәртип белән каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәү;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы тарафыннан тапшырылган мәгълүмат дөрес булмау.

Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлегенә бу турыда хәбәрнамә җибәрә.

Башка бюджетара трансферт бирүдән баш тарткан очракта, Министрлык,

карар кабул ителгән көннән алып эш көннәрендә исәпләнелә торган өч көн эчендә бу хакта Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органына хәбәр җибәрә.

12. Башка бюджетара трансфертлар Министрлык һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы арасында төзелә торган килешү нигезендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бирелә.

13. Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

башка бюджетара трансфертның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансферт күләме;

индустриаль (сәнәгать) парк (парклы) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгы исеме;

башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткече мәгънәсе;

башка бюджетара трансферт күчерү тәртибе һәм вакытлары;

башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәләренең) максатчан күрсәткечләренә ирешү һәм башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап бирү вакытлары һәм формалары;

алучының башка бюджетара трансферттан файдалануның максатчан күрсәткече (нәтиҗәләре) билгеләнгән максатчан күрсәткечкә ирешмәгән нәтиҗәләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан килешүдә каралган башка бюджетара трансферт алу буенча йөкләмәләрнең үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибе;

килешү шартларын бозган өчен якларның җаваплылыгы.

14. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелә торган башка бюджетара трансферт (С) күләме түбәндәге формула буенча исәпләп чыгарыла:

$$C = S \times N,$$

монда:

S – индустриаль (сәнәгать) паркның (паркының) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгының гомуми мәйданы, гектар;

N – индустриаль (сәнәгать) паркның (паркының) һәм (яки) сәнәгать мәйданчыгының 1 га мәйданын карап тоту нормативы ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

15. Министрлык башка бюджетара трансферт бирү турында карар кабул ителгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә имза кую өчен килешү проектын Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органына җибәрә.

16. Министрлык Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органыннан имзаланган килешүне алган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көн эчендә килешүгә имза куя.

17. Башка бюджетара трансфертлар килешүгә Министрлык кул куйганнан соң эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге бюджетына Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе Үзәк банкының Федераль казначылыкның территориаль органында ачылган шәхси

исәп-хисап счетына күчерелә. Муниципаль ихтыяҗлар өчен товарлар сатып алу, эшләр башкару һәм хезмәтләр күрсәтүгә бәйле булган очракларда, башка бюджетара трансфертлар Россия Федерациясенең сатып алулар өлкәсендә контракт системасы турындагы законнары нигезендә төзелгән контрактны (шартнамәне) кертkән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән биш көн эчендә килешү нигезендә бирелә.

18. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органы Министрлыкка башка бюджетара трансферттан файдалану турында хисап һәм килешүдә каралган формалар, сроклар һәм тәртип нигезендә башка бюджетара трансферттан файдалануның максатчан күрсәткеченә (нәтиҗәләренә) ирешү турында хисап тапшырырга тиеш.

19. Башка бюджетара трансферттан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансферттан файдалануның максатчан күрсәткече (нәтиҗәләре) һәм план елы нәтиҗәләре буенча фактта ирешелгән башка бюджетара трансферттан файдалануның нәтиҗәлелек күрсәткечен (нәтиҗәләре) чагыштыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

20. Әгәр башка бюджетара трансферт бирү елның 31 декабренә муниципаль берәмлек тарафыннан килешүдә каралган бюджетара трансфертлардан файдалануның максатчан күрсәткече (нәтиҗәләре) дәрәҗәсенә ирешү буенча йөкләмәләрне бозу рөхсәт ителгән булса, башка бюджетара трансферт муниципаль берәмлек бюджетыннан башка бюджетара трансферт бирү елыннан соң килә торган елның 1 апреленә кадәр тулысынча Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

21. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансферттан максатсыз файдалану өчен җаваплы.

22. Әлеге Тәртип нигезендә алынган, агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемена кире кайтарылырга тиеш.

Министрлыкның хисап финанс елында файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турындагы карары нигезендә, әлеге башка бюджетара трансфертларның калган өлешеннән артыграк булмаган күләмдәге акча агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетының әлеге башка бюджетара трансферт бирү максатларына туры килә торган чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен бирелгән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты керемена кире кайтарылырга мөмкин.

Әлеге Тәртип нигезендә алынган башка бюджетара трансфертларның файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемена күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты керемена Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә түләттерелергә тиеш.

23. Министрлык һәм Татарстан Республикасының дәүләт финанс контроле органнары килешү һәм әлеге тәртип белән билгеләнгән башка бюджетара

трансфертлар бирү шартларының, максатларының һәм тәртибенең үтәлешен тикшерүне гамәлгә ашыра.

24. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан башка бюджетара трансферт максатчан файдаланылмаган һәм (яки) аны бирү шартлары бозылган, шул исәптән Татарстан Республикасының муниципаль берәмлеге тарафыннан Татарстан Республикасы бюджетына акча кире кайтарылмаган очракта, аңа карата Россия Федерациясенең бюджет турындагы законнары белән күздә тотылган мәҗбүри түләттерү чаралары кулланыла.

25. Башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.